Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № XIII**

Котлы Бөкәш авылы 16 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында нигезләмәне һәм гражданнарның үзара салым акчаларын куллану тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясы, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 60 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11, 81 статьялары белән Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын куллану тәртибе турында өстәмә нигезләмәне расларга.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында нигезләмәне һәм гражданнарның үзсалым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибен раслау турында»2016 елның 26 маендагы XII номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга : Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет”

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов